# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәле авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**30 март 2024 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге башлыгынын 20.03.2024 ел 1 нче номерлы "«Яңа Имән авыл җирлеге Күтәмәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәл торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәле торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында" карары нигезендә 2024 елның 30 мартында 15.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән протокол төзелде. Гражданнар җыенына түбәндәге сораулар тәкъдим ителде.

«Яңа Имән авыл җирлеге Күтәмәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәле торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«1. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Күтәмәле авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);
2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Күтәмәле торак пункты чикләрендә юлларны кардан чистарту (тракторчы хезмәтләре өчен түләү);
3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Күтәмәле авылында триммерлар һәм генератор өчен запчасть һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу; МТЗ 82.1 тракторына хезмәт күрсәтү(ягулык-майлау материаллары, өстәмә асылмалы, тагылма җиһазлар, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү); халык күпләп ял итә торган урыннарны һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (сабантуй мәйданына төзү материаллар, сэхнэ сатып алу , скамейкалар сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү );
4. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары белән тәэмин итү (Күтәмәле авылында янгын сүндерү машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүченең хезмәте өчен түләү).
5. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Күтәмәле авылында - “Шамгун”, “Миннэхмэт” чишмәләрен тозекләндерү (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;
6. Яр буйларын, сулыкларны чистарту (Күтәмәле авылы сулыкларында агачларны кисү,шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
7. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аның янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (Күтәмәле авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарның һәйкәлен ремонтлау)?";

“ӘЙЕ” “ЮК”?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 174 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 136 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 136 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлегенең Кутәмәле торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. Түбәндәге сораулар буенча :

«Яңа Имән авыл җирлеге Кутәмәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Кутәмәл торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«1. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Кутәмәле авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);

2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кутэмэле торак пункты чикләрендә юлларны кардан чистарту (тракторчы хезмәтләре өчен түләү);

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Кутәмәле авылында триммерлар һәм генератор өчен запчасть һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу; МТЗ 82.1 тракторына хезмәт күрсәтү(ягулык-майлау материаллары, өстәмә асылмалы, тагылма җиһазлар, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү); халык күпләп ял итә торган урыннарны һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (сабантуй мәйданына төзү материаллар, сэхнэ сатып алу , скамейкалар сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү );

4. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары белән тәэмин итү (Кутәмәле авылында янгын сүндерү машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүченең хезмәте өчен түләү)

5. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Кутәмәле авылында - “Шамгун”, “Миннәхмәт” чишмәләрен тозекләндерү (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;

6. Яр буйларын, сулыкларны чистарту (Кутәмәле авылы сулыкларында агачларны кисү,шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

7. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аның янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (Кутәмәле авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарның һәйкәлен ремонтлау)?";- карарны кабул ителгән дип санарга

“ӘЙЕ” “ЮК”?».

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Яңа Имән авыл җирлегенең Кутәмәле мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Р.Ф.Гараев